ГЛАВА БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Молодежная, д.19, с. Большие Меми, 422588

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ОЛЫ МЕМИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яшләр ур., 19 нче йорт, Олы Меми авылы, 422588

Тел.: (84379) 36-0-32, факс: (84379) 36-0-32.

12.04.2024 № 1

КАРАР
Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Олы Меми авыл җирлеге Олы Меми авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 22.11.2013 № 909 (29.11.2023 № 1532 редакциядә) 2 пункты нигезендә, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлегенең Олы Меми авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 31 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә сез ризамы?-

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (товар китерүче хисабына товар китерү пунктына кадәр илтеп җиткереп, Олы Меми авылының юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу),- дигән сорау буенча 2024 елның 12 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены протоколы төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә җыенда катнашкан 203 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 113 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 113 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1 Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлегендә гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләре- дөрес дип таныргa.

2 «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлегенең Олы Меми авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 31 октябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә сез ризамы?

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (товар китерүче хисабына товар китерү пунктына кадәр илтеп җиткереп, Олы Меми авылының юлларын ремонтлау өчен вак таш сатып алу),- дигән сорау буенча карарны танырга.

3.Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлегенең Олы Меми авылында гражданнар җыены нәтиҗәләрен Олы Меми авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Г.А. Фомина